ЛЕНИНОГОРСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД ЛЕНИНОГОРСК
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
ЛЕНИНОГОРСК
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

13.10.2022 г.Лениногорск № 101

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Лениногорск шәһәр Советының 2014 елның 26 февралендәге «Җирле салымнар буенча недоимканы, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләттерүгә өметсез дип табуның өстәмә нигезләре турында» 126 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында (2014 елның 25 июлендәге 147 номерлы, 2017 елның 6 июлендәге 108 номерлы ред.)

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясының 3 пункты, Лениногорск муниципаль районының Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Лениногорск шәһәр Советының 2014 елның 26 февралендәге «Җирле салымнар буенча недоимканы, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләттерүгә өметсез дип табуның өстәмә нигезләре турында» 126 номерлы карарына (2014 елның 25 июлендәге 147 номерлы, 2017 елның 6 июлендәге 108 номерлы ред.) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

Совет карарының преамбуласында «Россия Федерациясе Федераль салым хезмәтенең 2010 елның 19 августындагы «Түләттерергә өметсез дип табылган недоимкалар, штраф һәм процент буенча бурычларны пеня, штраф һәм процентлар буенча недоимка һәм бурычларны исәптән төшерү тәртибен раслау турында» N ЯК-7-8/393@ номерлы боерыгы сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Башлыгы урынбасарына, икътисад, салымнар, финанслар һәм эшмәкәрлекне үстерү буенча даими комиссиягә йөкләргә.

3. Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми интернет-сайтында һәм Татарстан Республикасы хокук порталында бастырып чыгарырга.

Лениногорск шәһәре
муниципаль берәмлеге Башлыгы
Лениногорск шәһәре мэры Р.Г. Хөсәенов